


Чаян

ISSN 0134-384

САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ * ИЮНЬ * 2016 * КАЗАН

11



Алексей МАМАЕВ

АННАН-МОННАН

ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

Сәламәтлек саклау министрлыгы, рәсәйләрнең дару сатып алу мөмкинлеге кимүенә таянып, милләт сәламәтлеге артты, дип белдерде.

Рәсәйдә ниһаять аңлаешлы социаль-икътисадый программа барлыкка килде — "Акча юк, ләкин сез бирешмәгез!"

Европа өстендә Циклон һәм Антициклонның каты бәрелеше куерырга маташа.

Америка хокук яклаучылары актәнлеләрне евроамериканлар дип атарга тәкъдим итәләр.

Кадыйров исеме бирелми калган Питер күперенең ян киртәсен җимергәч, ул гафу үтенергә булган.

Ерак Көнчыгышта мэрларны тоту сезоны дәвам итә.

Экспертларның чутлавы буенча, Рәсәй икътисады инде җиде мәртәбә төпкә төште.

Дагстан тагын «по здачи ИГЕ па рускаму на сто балав рекорд паставил».

Безнең команда җиңел атлетика буенча алтын мельдонист булды.

Аноним пластик хирургия яратучылар җәмгыяте үзенең сафларына беренче әгъзалар кабул итте.

Табиблар тәкъдим итә: сәламәт тормыш рәвешен гади барлардан башлап, спорт-барларда дәвам итү кирәк!


Кибеткә яңа товар кайткан. Консервантлы су. Консервант сыйфатында 40% лы спирт кулланыла.

Ил буйлап чираттагы турга илебезнең примадоннасы Боря Моисеев чыгып китте.

Тарихчылар, 8 Мартны уйлап чыгарган Клара Цеткин белән Роза Люксембургны чынлап та чәчәк сатучы булганлыкларын ачыклаганнар.

Кызыл диплом иясе, «фри» бәрәңгене бургер белән бутаганы өчен Макдоналдстан куып чыгарылган.

Полиция ялган Twix чыгаручы фабрика эшчәнлеген туктаткан.



Игорь КИЙКО

ШОМБАЙ болай диде...




Хөрмәтле Чаян! Конституция буенча җир асты казылмалары барлык халыкның байлыгы. Җир астында ятканда, әлбәттә. Аларны чыгару белән, шунда ук компанияләр һәм аларның топ-менеджерлары милкенә әйләнәләр...

Л. ГАЙНУЛЛИН

ТҮБӘН КАМА

– Закон буенча безнең дә һәрберебез үзенең алты сутыенда файдалы казылмалар чыгара ала, – диде Шомбай ага. **– Бәрәңге, кишер, чөгендер...**


Валентин ДРУЖИНИН



Николай ВОРОНЦОВ

Алмаз ХӘМЗИН

СОҢГЫ НАМУС

Язучылар кызды...
Барчасы тели
"Халык язучысы" булырга!
Ә халык белми хәтта шигырен,
Хикәясен телгә алырга.

Иҗаты сүнгәннәр,
Онытылганнар
Кызды. Берсен-берсе таптыйлар.
Ай, азындылар! Җитми аларга...
Тукайны да узып атлыйлар...

Исән булса Тукай,
Ни әйтер икән?..
— Миңа бирегез әле? — димәс!
Сорап шакымас түрә ишеген,
Хурлыкка Даһиебыз төшмәс!

Язучылар азды...
Тибеп намусны,
Бүләләр хәзер соңгы "казны".
"Халык язучысы" акчасына
Аларның нәфесләре кызды.

РеКЛаМа

● Балагыз белән кирәк хәтле утыра алам. Утырулар буенча бай тәҗрибәм бар.

● Эш һәм ябыгу – берьюлы. Порт складлары.

● Тәҗрибәле проводник арзан бәягә төнлә сезне өегезгә кадәр илтеп куя. Үзе белән һәрвакыт фонарь һәм электрошокер йөртә.

● Клиентларыгыз күбәйсен дисәгез, ешрак судка мөрәҗәгать итегез.

● Нәфис медицина клиникасы ирләрнең кулларын хатыннары күрсәткән урынга тегеп куя.

● Бурычларны кайтару һәм кайтармау буенча күнегүләр уздырабыз.

● Тәҗрибәле бухгалтер сезнең бухгалтериягезне бернинди салым инспекциясе дә очына чыга алмаслык итеп бутый ала.

● Уртак хуҗалык алып бару өчен үз хуҗалыгы булган кеше кирәк. Алты сутый тәкъдим итмәскә.


● Курсовой, диплом эшләре, кандидат һәм докто диссертацияләре, министрлык отчетлары, регионнар өчен үсеш программалары язам...



Валерий ТАРАСЕНКО

ТИШЕК КОПЧӘК

Виталий ПОДВИЦКИЙ



Виталий ДУБИНИН



АРАКЫ түрә булмасын

Иртәме-соңмы һәр машина хуҗасы алдында сорау туа: «салган» килеш рульгә утырыргамы, юкмы? Ярый да ул башы буталган хәлдә бөтен дөньяга кулын болгап, «тимер атына» атланып китмәсә. Әгәр киресенчә килеп чыкса?

Күптән түгел Интернетта Чаллы шәһәрендә юл инспекторларының бер автомобильне туктатулары турындагы видеоязма игътибар җәлеп итте. Менә аның ишегеннән, капчык кебек, йөртүчесе бүселеп төшә, һәм инспекторга томанлы карашын төбәп, авазлардан сүзләр төзергә маташа. Үзенең исем-фамилиясе турындагы сораугa ул җавап бирә алмый. Шулай ук яшәгән урыны, хәтта күпме эчкәнлеге турында да бер сүз дә әйтә алмый. Аның каравы, тирә-юньгә хәмер исе аңкытып, Россия президентының исемен чатнатып әйтеп бирә.


Бу вакыйганы, ни дисәң дә, уңышлы тәмамланган дип әйтергә була. Чөнки бу сәрхуш йөртүче беркемгә дә зыян китерергә өлгерми. Ә охшаш очракларның фаҗига белән тәмамланганнары күпме! Узган ел эчендә генә Татарстан юлларында 113 кеше һәлак булды, һәм 527 кеше имгәнде. Ил буенча саннар тагын да куркынычрак – бер ел эчендә исерек йөртүчеләр аркасында бер уртача район үзеге юкка чыга.

Шулай да, законнарга төкереп, оста йөртүчегә хәмер комачауламый дип санаучылар белән нишләргә соң? Күрше Удмуртиядә, мәсәлән, депутат Энвил Касыймов исерек «автоҗайдак»ларны, шулай ук аларны шундый хәлгә җиткерүдә катнашкан кешеләрне судка тартырга тәкъдим иткән. Ләкин күпсанлы юридик киртәләр барлыкка килү сәбәпле, бу төпле фикер тикшерү стадиясендә тоткарланып калган.

Татарстанда исә башка «айнытучы» ысуллар. Бернichә ел элек республиканың ЮХИДИ сайтында «Куркыныч йөртүче» дигән исемлек булдырылды. Ил үзенең исерек каһарманнарын белергә тиеш бит! Бу «хурлык тактасы» даими рәвештә тулыландырып барса да, аварияләр саны нишләптер кимеми. Хәтта узган ел кабул ителгән җаваплылыкны көчәйтү турындагы закон исерек килеш машина йөртергә яратучыларны куркытмады. 200 мең сум штраф йә ике ел төрмә җитәрлек җәза түгел, күрәсең – закон гамәлгә кергәч, бу статья буенча егерме мең кеше җавапка тартылды инде.

Күптән түгел Казандагы юл хәрәкәте постларының берсе янына «салмыш» йөртүче килеп туктаган һәм... җәяүлеләрдән аны коткаруны сорап мөрәҗәгать иткән. Машинасы эчендә тыныч кына хәмер йотып утырган чакта ул бер төркем кешенең аны күзәтеп торуына игътибар иткән. Җәяүлеләрнең машина йөртүчеләрне аек килеш тә бик өнәп бетермәгәнен аңлаган бичара якындагы пост янына элдертүне хәерлерәк күргән. Инспекторлар аны эзәрлекләүче кеше күрмәгәннәр күрүен, тик куркак йөртүченең үтенечен игътибарсыз калдырмаганнар: автомобилен штрафстоянкага, ә үзен вакытлыча тоткарлау камерасына урнаштырганнар. Мондый ахмак хәлгә калмас өчен кайберәүләргә «Акылыңа аракы түрә булмасын» дигән әйтемне истә тоту артык булмас иде.

Людмила САФИУЛЛИНА



Виктор ФЁДОРОВ



Александр КОСМЫЛИН



Николай ВОРОНЦОВ



• • •

Рәсәйдә хәрәмнән килгән хезмәт хакы җыелган күл тапканнар. Берәүнең дә аны күргәне юк, әмма юк-барга ышанучылар ышана моңа.

• • •

Рәсәй түрәләрен санкция белән куркыту — кошларга каршы көрәшеп, урман яндыру кебек гамәл. Бөтен тереклек янып бетәчәк, ә кошлар башка җылы урынга очып китәчәк.

• • •

— Җылы сыра, тирләүчән хатын-кызларны һәм черкиләрне яратасызмы?

— Юк, сез нәрсә?!

— Алай булгач, язып куябыз — ял итү вакытыгызны кыш көне алырсыз.

• • •

ЗАГСта ук кисәтеп кую зарар итмәс иде: монда әйтелгәннәрнең барысы да сезгә карата каршы килүе бик мөмкин…

• • •

— Кая гына төкермә — бөтен җирдә дошман!

— Бәлки сирәгрәк төкерергә кирәктер?

• • •

Кызык арифметика. Лукойл вице-президентының улы 6 сәгать буе машинасында Мәскәү буенча куып йөргән. Видеоязмалардан күренгәнчә, 340 юл йөрү кагыйдәсен бозу очрагы теркәлгән. Бу 580 мең сум чамасы штрафка тәңгәл. Барысын кушып исәпләгәндә, 364 тәүлеккә ябып кую, 15 мәртәбә машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителүе 18 елга җыела. Җинаять кодексының 3 нче статьясы буенча, җәмгысы — 8 ел. Нәтиҗәдә, 15 тәүлеккә шартлы рәвештә утырту килеп чыккан.

• • •

Философия профессоры имтихан вакытында студентларга “Ни өчен?“ дигән бер генә сорау биргән:

“Ә ни өчен юк?” дип җавап биргән студент иң югары балл алган.

• • •

— Ничек уйлыйсың, әгәр дә Чубайсны Гадәттән тыш хәлләр (МЧС) министры итеп билгеләсәләр?

— Иң элек ул МЧСта Гадәттән тыш хәлләр, бәла-казалар һәм катастрофалар департаменты оештырыр, аннан соң шул министерствоны приватизацияләргә тәкъдим итәр.



ЫШАНЫЧСЫЗ КӘНӘФИ

Казанның Мәскәү районының ЮХИДИ башлыгы Андрей Батьковның утырган кәнәфие селкенә башлаган – ул ришвәт алуда тотылган. Аңа берәү ремонттан чыккан КамАЗының техник куркынычсызлык таләпләренә туры килү турында таныклык сорап мөрәҗәгать иткән. Йөк машинасы андый хәлдә булмаган, тик башлык үтенечне кире какмаган. Эшләнгән эш өчен рәхмәт йөзеннән үтенүче аңа 6 мең сумлык кәнәфи китергән. Ләкин районның баш гаишнигына кәнәфиендә озак утырырга туры килмәгән – аны 250 мең сум штрафка тартканнар һәм бер елга җитәкче урынында утыру хокукыннан мәхрүм иткәннәр.

ДЕПУТАТ СЕРТИФИКАТЫ

Дәүләт Думасы депутатларының чираттагы тәкъдиме, турысын әйтик, аптырашта калдырды. Бу юлы халык мәнфәгатьләрен яклаучылар «Өйләнешүчеләр сертификаты» дигән нәрсә уйлап чыгарганнар. Һәр гаилә төзергә җыенучыны сыйфатлы нәсел дәвам итү мөмкинлеген тикшерү тәкъдим ителә. Шунда ук закон проекты авторлары өстенә уңайсыз сораулар ява башлаган: никахлашучыларның үрчү сәләте ничек тикшереләчәк, югары күрсәткечләр берничә хатын алу хокукы бирәме, бала булдыру мөмкинлегеннән мәхрүм яшьләргә нишләргә? Фикер алышу барышында мондый «закон»нарның узган гасырның 30-40 нчы елларында Европа илләренең берсендә булганлыгы ачыкланган. Депутатлар сораулар өстендә баш ваткан арада, каршы тәкъдим туган: һәр депутатны акыллы тәкъдимнәр ясау сәләтенә тикшереп, «Депутат сертификаты» кертергә.

ЗАКОНЛЫ КАРАКЛАР

Италиянең Югары кассация суды кибетләрдә ризык урларга рөхсәт иткән. Супермаркеттан бер кап сосиска һәм бер телем сыр эләктергән украиналының эшен караганда, суд ач кешене җәзага тарту кешелексезлек дигән нәтиҗәгә килгән. Ярлы гражданнарның саны көн саен 600 кешегә артып бару гаделлек сагында торучыларны мондый адымнан туктатмаган. Суд карарын бөтен итальяннар хуплап чыккан. Кибет хуҗаларыннан башка, билгеле.



• • •

Европаның һәр футбол чемпионаты алдыннан җанатарлар ике төркемгә бүленә: безнең җыелма команданың җиңүенә ышанучылар һәм футболда берни дә аңламаучылар.

• • •

Россия командасы футбол чемпионатында җиңгәндә нишләргә кирәк?
«ФИФА-2016» компьютер уенын өзеп куярга һәм йокларга ятарга!

• • •

Россиядә һәрвакыт ике бәла иде... хәзер аңа футбол өстәлде .

• • •

Матч алдыннан уенчыларның берсе судьяны кисәтә:
– Сызгырма, алайса акча булмас!

• • •

Кыз күптән түгел танышкан егетенә:
– Сез футболчыдыр, әйеме?
– Ә сез каян белдегез?
– Искиткеч кочаклашасыз һәм үбешәсез!

• • •

Футболчы тренировкадан соң тренер янына килә:
– Мин команданы ничек көчәйтергә икәнен беләм!
– Нәрсә, син бездән китәсеңмени?

• • •

Тупны капкага кертү генә аз, моны әле капкачыга тидермичә эшләргә дә кирәк.



Валентин ДРУЖИНИН



Игорь КИЙКО

ТУП ХИКМӘТЛӘРЕ

Футбол тарихы һәрвакыт төрле мәзәк хәлләр һәм кызык вакыйгаларга бай булган. Матчларда кайчагында аңлатып булмый торган, гаҗәеп нәрсәләр булып торган. Футболны юкка гына спортның беренче төре дип атамыйлар бит. Шуңа күрә бу уенда булган мәзәк хәлләр дә башкалар арасында беренче урында тора.


Риддинг шәһәре өчен уйнаучы капкачы Джим Тейлор футбол сезонының 27 нче матч барышында капкасына 456 туп керттергән. Бер матчка 17 туп дигән сүз бу. Ә Стокгольмның яшьләр командасы һөҗүмчесе уеннарның берсендә тупка кагыла да алмаган. Шуңа да карамастан, команда 18:0 исәбе белән җиңгән.

Аргентинаның “Барика” командасы сакчысы үз капкасына җиде туп бәреп керткән. Тренер, аның сәләтләрен тулырак файдаланыр өчен, һөҗүмче итеп күчергән. Тик футболчы беренче матчта ук үз командасының капкасына яңа туп бәреп керткән.

Ватиканның футбол беренчелегендә «Музейлар җыелма командасы», «Телепочта», «Гвардеецлар», «Банк», «Библиотека» командалары уйный.

Италиянең «Фиорентина» командасы банкаларга тутырылган стадионнарының һавасын сатарга булган. Җыелма һавада өч “хуш ис” булган: “Трибуналар сулышы”, “Җиңү исе” һәм “Чишенү бүлмәсе атмосферасы”.

Футбол тарихында иң “тиз гол” Австралиядә кертелгән. 1995 елда уен башланып 3,67 секунд вакыт үткәч, «Аделаида Сити» уенчысы Дэмьен Мори каршы команданың капкасына беренче тупны кертә.



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Сергей КОКАРЕВ

Хамис ГАРИПОВ

КЫЗ УРЛАУ

Кыз урларга барган идек “Ока” белән,
Кире уйладык әле ул кызны күргәч…
Кыз, дигәнең бик тә юан булып чыкты,
Кирәк монда “ГАЗель” яки берәр тягач!

НИГӘ ЭССЕ?

Казанымда хәзер нигә эссе?..
Җитсен генә безнең түземлек!
Җылы яктан күпләп халык килә,
Шулар белән бергә эсселек!

Илдус ДИНДАРОВ

***

Үрдәк мескен тавык күкәйләрен
Басып чыгара да ояда,
Үземнеке диеп чебешләрне
Юындырмак була буада.

Түрәләр дә гел “диңгез”гә әйди,
“Реформа” дигән им биреп,
Өйрәтмәгәч йөзү әмәленә,
Йөри ярда халык тилмереп.



Игорь КИЙКО



Александр СЕРГЕЕВ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Тормыштан зарланма — аның булмавы да мөмкин иде бит.

Хатын-кызлар һәм филләр рәнҗетүне беркайчан да онытмыйлар.

Тормыш сез уйлаганча гади түгел. Ул күпкә гадирәк.

Гомер үзебездән башка уза: без һәрвакыт үткәннәр белән өмет арасында.

Тормыш ашыгып язган хат шикелле: кыска һәм хаталар белән тулы.

Ирләр киләләр һәм китәләр. Ә кайберләре кала да әле.

Олыгайган саен, тән һава үзгәрешләренә сизгеррәк була бара, ә һава торышы һаман ешрак һәм ешрак үзгәрә башлый.

Тормышта һәрнәрсә дә өмет булып башлана, һәм гадәт булып тәмамлана.

Гомер буе абынып яшәүгә караганда, бер тапкыр егылу хәерлерәк.


Тормыш сабаклары араларындагы тәнәфесләр белән гүзәл.

Әгәр дә син тугансың икән, тормыштан зарланырга соң инде.

Дусларың һәм дошманнарың бар икән, бик яхшы: дуслар ярдәм итәр, дошманнар өйрәтер.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)

Александр АЛЁШИН



Александр ЛЕВИТИН



Антон МАКУНИ

Деточкин-2

— Деточкин, — дип кычкырып укыды бүлек капитаны Петров, тоткарланган кешенең документына карап. Аннан соң, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, сорап куйды:

— Син теге Деточкинның туганы түгелдер бит?

— Улы.

— Димәк, әтиең гадәтен куасың?

Тоткарланучы нәрсә әйтергә белми, иңнәрен кысты.

— Аңлашылды... һаман шул эздән барасың, ызначит?

— Шул эздән...

— Ә акчаларны кемгә? Балаларгамы? — дип, мәкерле елмаюы йөзенә чыкты.

Тоткарланучы башын какты.

— Ике атнага өч машина куу очрагы, — диде капитан, компьютерында казынып.

— Өч, — диде, төзәтеп, Деточкин. — Ләкин мин куганнарымны кире кайтардым...

— Кайтардыгыз? Ә цемент ташый торган машинаның цементын кая куйдыгыз?

— Эшләгән эшкә акча аз бүлеп бирәләр, ә капкалар бик нык кыегайган, менә шуңа мин...

— Монда капканың ни катнашы бар? — дип тавышын күтәрә башлады полицейский. — Ә катокның нәрсәгә кирәге чыкты?

— Әйтәм ич, акчаны бик аз бүлеп бирәләр, спорт мәйданына асфальт җәяргә кирәк иде... Ә башта бульдозер белән...

— Бульдозер турында мин синнән сорамыйм да әле, — дип, ул кулын селтәп куйды.

Шул вакыт кабинетка кулга алынган кеше турында белешмәләр җыярга җибәрелгән лейтенант Петров килеп керде.

— Менә! Деточкин — балалар йортының директоры.

— Сез — директормыни?

Капитан урыныннан ук сикереп торды.

— Директор, — диде Деточкин. — Ләкин акчаны бөтенләй бирмиләр, ә балаларга спорт мәйданчыклары һәм башка бик күп нәрсәләр кирәк...

Деточкин тынды. Капитан уйларына чумды.

— Менә нәрсә! — диде ул бераз торганнан соң. — Бөтен урлаганны кире кайтарып бирүегез сәбәпле, без сезне, гражданин Деточкин, тоткарлый алмыйбыз.

— Менә нәрсә... лейтенант, Юл хәрәкәте хезмәтендәгеләргә әйт, коттеджлар бистәсенә барсыннар, анда “крутой”лар еш кына тизлекне арттырып йөри... Тырышсыннар. Әйтсеннәр, подшефный балалар бакчасына, дисеннәр. Аңладыңмы?

— Так точно! — диде дә лейтенант, ядрә тизлегендә ишектән чыгып китте.



Василий АЛЕКСАНДРОВ

Искәндәр БОРҺАНОВ

ВОКЗАЛ ЯНЫНДА

Вокзал янында Шәпиев янына кырынмаган бер бәндә килеп туктады һәм, хәмер исе аңкытып, Түбән Корыганга хәтле билет алырга дип илле сум сорады. Имештер, аны өч тапкыр талаганнар, һәм ул инде ике атна буе өенә кайтып китә алмыйча тилмерә...


Берничә минуттан йончыган кыяфәтле хатын аннан дару алу өчен илле сум сорап алды. Аның менә-менә баласы туарга тиеш икән, ә андый чакта дарусыз берничек тә булмый...

Шәпиевкә күзләре шешенгән зәңгәр борынлы ир якынлашкач, ул ничектер җыелып, киеренке хәлгә килде...

— Сезнең акыллы, укымышлы кеше икәнегез әллә каян күренеп тора, – диде ул, – бу вокзал ансамбленең архитекторының кем икәнен әйтмәссезме?

Шәпиевнең эченә җылы йөгерде, карале син аны, бомжлар да акча кайгысы белән генә йөрми икән бит, сәнгать белән кызыксынучылары да бар икән... Күңеле күтәрелеп, ул иргә йөзлек тоттырды. Сәнгать һәйкәлләрен саклау фондынамы, әллә җанын дәвалау өченме...

Шәпиев кесәләрен актарып карады. Акча сыралык кына калган иде. Түтәй янына тагын китеп булмады... Ул сырахanә янына килде һәм анда үзеннән акча сораганнарны күреп алды. Алар беркатлылыкның психологик тамырлары турында җанлы әңгәмә алып баралар иде...



Александр АЛЁШИН

ДИМӘК, СЕЗ КАРШЫ ТҮГЕЛ?

Алексей МАМАЕВ

Ләззәт КӘРИМУЛЛИН

ФИКЕР БОРМАЛАРЫ

- Акчаны юк-барга да җитәрлек итеп эшләргә кирәк.

- Дөреслек кайда? Буш сораулар биреп башымны катырмагыз.

- Илебез бик бай. Тик хәзерге вакытта вакытлыча ярлы хәлдә.

- Нигә ахмак җаваплар акыллы сорауларга караганда күбрәк?

- Артык акча хәтта акча ясаучыларда да булмый.

- Фикерләр килә һәм китә тора, ә мәгънәсезлек кала.

- Медицина кыйммәт булганда, вакыт – дәва.

- Кеше булдыра алганча яши. Ә булдыра алмаса – җәфа чигә.

- Ахмаклык җиңелрәк һәм тизрәк үзләштерелә.

- Бары акыллы кеше генә кайчагында үзен җүләр итеп тоя ала.

Олег ПРЯНИЧНИКОВ



Җәйге иртәдә шәһәр урамы буенча иске тимер-томыр төягән йөк машинасы бара иде. Кинәт ул сикәлтәгә барып менде, һәм тимер өеменнән чуен канализация люгы тәгәрәп чыгып, дөбердәп асфальт өстенә төшеп ятты.

Машина йөртүче югалтуны сизмәде, һәм люк кое каплаган шикелле ятып калды.

Бер сәгатьтән соң бу урынга шәһәрнең канализация идарәсенең коелар бүлеге начальниге килеп чыкты. Ул кинәт пәйда булган люкка игътибар белән карап, бераз башын кашып торды. Эшкә барып җиткәч әмер бирде: фәлән-фәлән җирдәге канализация коесында профилактика эшләре үткәрергә.

Профилактика үткәрергә ике слесарь җибәрелде.

Эшне башлар алдыннан алар, әлбәттә, “тамак чылатып” алдылар.

Урынны тиешенчә рәшәткә белән әйләндереп алып, люкны күтәрделәр… Анда асфальт иде. Алар артыграк “җибәргәннәрен” аңлап алдылар. Люкны әйбәтләп кенә урынына куйдылар да, конторага әйләнеп кайтып, башкарылган эш турында сөйләп бирделәр: торбалар чистартылды, краннар майланды, кое капланып куелды.

Икенче көнне төпченергә яратучы начальник коены үзе тикшереп карарга булды. Кирәкле инструмент алып шунда китте. Люкны күтәреп карады… ә анда асфальт иде…

Чын мәгънәсендә гадел кеше буларак, шул ук көнне ул яңа приказ чыгарды: “Йөкләнгән эшне сыйфатлы башкарганнары өчен слесарьлар М. һәм Б.ны акчалата премия белән бүләкләргә”.

«Карале син аларны, — дип уйлады начальник, — люкны асфальтка ничек беркеткәннәр, аны бит бернинди бомж да металл кабул итү пунктына илтеп тапшыра алмаячак! Аны хәзер бары бульдозер гына куптара алачак!»



ЮЛ ГАЗАБЫ

Хөрмәтле редакция! Бүгенгесе көндә дөньяның теләсә кайсы почмагына күз ачып йомганчы барып җитәргә була, акчаң гына булсын. Ә менә үз бакчаңа барып җиту җиңелләрдән түгел...

Бакчам Казаннан 20 чакрым ераклыкта, Көлсәет бистәсендә урнашкан. Бистәне мегаполиска кушсалар да, бердәнбер 88 нче санлы автобус маршруты гына йөри анда. Ярый ла, кышын, көзен маршрут халыкны ташып өлгерә. Ә менә бакча сезоны ачылуга бакчачылар кул арбасы һәм үсентеләренә урын табалмый интегә. Халык түзем, ә менә үсентеләр этеш-төртешле көрәшне авыр кичерә. Инде хәзер үк интегеп үстергән уңышны көзен ничек итеп алып кайтырбыз икән, дип борчылабыз.

Г. РӘШИДОВА

КАЗАН

ӨМЕТСЕЗ ХЫЯЛЛАР

Кадерле Чаян! Америкада кайбер юлларны төзегәннәр, ә картада күрсәтергә онытканнар дип сөйлиләр. Ә безнең Емелькино җирлегендә киресенчә, биш авыл кергән юлны картада күрсәткәннәр, ә төзергә җыенмыйлар да.

Емелькино авылы "үзәгенә" өч юнәлештә барып җитәргә була. Дөрес, җәйге коры һава шартларында гына моны эшләргә мөмкин. Ә яңгырлы көндә пычракка баткан машинаң йә сазны ерып чыга, йә трактор артыннан йөгерергә туры килә.

Күп еллар кая гына язып карасак та, файдасы булмады. Безнең зар-интизарарыбызга бер генә җавап килде: акча юк! Шулай да үткән ел безнең проблеманы ишеттеләр. "Главтатдортранс"тан: юл булачак сезгә, дигән өмет хаты килде. Ләкин кайчан, ничек төзеләчәге турында ләм-мим бер сүз юк иде. Бары берничә аңлашылмаган фраза: "мөһим тәртиптә социаль-әһәмиятле объектлар дип тапканда һәм җитәрлек күләмдә финанслау мөмкин булган очракта..."

Әлегә куркыныч урыннарда сак булу билгеләре кую белән генә чикләнделәр. Күрәсең, "социаль-әһәмиятле объектларны җитәрлек күләмдә финанслау" шуның белән тәмам...

Емелькино авылы халкы

АКСУБАЙ районы,
ТАТАРСТАН

Александр СЕРГЕЕВ



Эрнест ДЫШАЕВ





• • •

Төнлә урманда албасты, убырлар җыелганнар да, бәхәсләшә башлаганнар: канны кем шәбрәк суыра? Ун-унбиш минуттан таралышканнар: аларны черкиләр изалап бетергән.




Вячеслав БИБИШЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ



Валентин ДУБИНИН

ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

Госман ГОМӘР

ӨЧ БОРЫНГА БЕР ҺӘЙКӘЛ

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң татар матбугаты яңа сулыш алып яши башлады. Иң әүвәл татар һәм урыс телләрендә яшьләр өчен мөстәкыйль гәзитләр дөнья күрде. Аннары “Чаян”, “Азат хатын”, “Татарстан коммунисты”, “Пионер” журналлары кабат чыгарыла башлады. Яшьләрнең зур активлыгы белән “үсү юлы” альманахы (соңрак “Идел” журналына әйләнде). Инде Бауман урамындагы мәшһүр Матбугат йорты кулмәгенә сыешу кыенлашты. Тагын бер матбугат комбинаты торгызу зарурлыгы туды. Югары җитәкчелек тарафыннан төзелеш өчен безгә өч урын тәкъдим ителде. Беренчесе — Дзержинский урамындагы, Тукай телендә “Микитин циркы” дип йөртелгән иске цирк урыны. Икенчесе — Кабан күле буендагы бушлык, бүгенге “Татэнерго” бинасы тирәләре күрсәтелде. Өченчесе — Кәҗә бистәсенең басу капкасы, дөресрәге, сары чәчәкле болын башы. Сазлыктагы кыйшайган, ярым җимерелгән йортларны күчергәндә, менә дигән тигез урын үзе.

— Гумеров, чакыр Долговны, урын сайларга киттек, — ди Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Ш. Хамматов идарә сәркатибенә. Долгов Михаил Филиппович — элеккеге Татарстан радиотапшырулар комитеты рәисе, күптән түгел генә гәзит-журналлар нәшрияты директоры булып эшли башлады. Җитәкче урыннарда эшләгән, югары әхлаклы Зәй керәшене. Сүзен үлчәп кенә сөйли. Бераз куркаграк та. Инде түбәнгә таба тәгәрәү полосасына кергән. Шуңадырмы, Хамматов аны еш кына “редакция завхозы” дип атый. Үзенең гел биеклектә каласы килгәндер, бәлкем.

Урын мәсьәләсендә Кәҗә бистәсенә тукталдык. Әйткәнемчә — иркенлек.

— Бу йортларны нишләтербез икән? — дип шикләнә калды Долгов.

— Тунаков бер ай эчендә күчереп бетерә аларны, — ди Шәмси Хәбибуллович, Казан шәһәр Башкарма комитетына ишарәләп, һәм сүзен кистереп әйтә:

— Без синең белән, иптәш Гумеров, бу төштә Долговка унөч катлы (Казанда беренче биек бина) һәйкәл куячакбыз!..

Ирония — ирония дә бит, өч ел эчендә заводтай цехлары белән унөч катлы нәшрият йорты сафка бастырылды.

Ә “һәйкәл” кемгә? Өчебезгә тигез бүленергә тиеш ул! Арадан үземне сызып калдыра алмыйм бит инде. Заман түрәсе булып йөргән чаклары бар иде абзагызның...



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 9, 1962

– Нәрсәгә шатландыгыз, миссис Джонс?
– Менә, илебезнең чәчәк атуы турында мәкалә таптым!



Иосиф БОБРОВИЦКИЙ, «Чаян» № 15, 1977

– Карале, өр-яңа район, ә инде җир асты кичүе ясаганнар!

ХӘРБИЛӘРНЕҢ ХӘРБИЧӘ...

– Иптәш старшина, сезнең приказыгыз үтәлде!

– Мин бернинди дә приказ бирмәдем бит.

– Ә мин берни дә эшләмәдем.

***

Прапорщик:

–Машинада бәрәңгегә барырга кем тели?

Ике солдат алга чыга.

– Рәхмәт, егетләр! Калганнарыгыз җәяү барачак!



Виталий ФЕОКТИСТОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Валентин ДУБИНИН



ЧУАР ПРЕССА

ГОССОВЕТ һӘМ МӘХӘББӘТ

Яңа гына өйләнешкән яшь кытайлар беренче никах төннәрен кәтеп алып, аны Конституция күчереп язуга багышлаганнар. Мондый фидакарь эш белән яшьләр Кытай Компартиясе идеяләренә тугрылык белдергәннәр. Яшь парлар әйтүенчә, алар гомерләре буе “беренче никах төнәрендә туган онытылмас күңелле истәлекләрне саклаячаклар. КХРның конституциясе 15 мең иероглифтан тора.

КҮЗЛЕК

Калифорниянең хәзерге заман сәнгате күргәзмәсендә кемдер мәзәк ясар өчен идәндә күзлек калдырган. Бернечә минуттан аның янында күргәзмәгә килүчеләр җыелышканнар. Күзлекне фотота төшергәннәр, арт-объекның оригинальлеге турында фикер алышканнар, тирән мәгънә эзләгәннәр, поп-арттагы яңа күренеш белән хозурланганнар.

ГАЕПСЕЗГӘ ГАЕПЛЕ

Гарәп Әмирлекләрендә хатыны, иренең хыянәт итүендә шикләнеп, җентекләп аның телефонын тикшергән. Аның сөяркәсенең фотосын һәм хатларын үзенең гаджетына күчергән. Фаш ителгәннән соң, ир полициягә мөрәҗәгать иткән. Нәтиҗәдә, хатынга, Әмирлекләр гражданкасы булмау сәбәпле, штраф салганнар һәм хуҗасының рөхсәтеннән башка электрон информация күчергән өчен илдән депортацияләгәннәр.

Сергей ЕРМИЛОВ



ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлаячак. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»ны катлаулыкларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.

Бу очракта язылу индекслары татарча журналга – П2438, ә русчасына П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Алар буенча Россия һәм Татарстан укучылары языла ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып балкып керсен!




Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр


Фил КИНГ (АКШ)


Павел КУЧИНСКИЙ (Польша)



Марк ПАРИЗИ (Франция)


Генри БЮТНЕР (Германия)



• • •

— Бер ел элек 8% ка ипотека алдым. Ике миллионга фатир вәгъдә иттеләр һәм шул ук бәягә эчен яхшылап бизәрбез, диделәр.

— Шуннан нәрсә?

— Шуннан-шул, әле ул йортны төзи дә башламаганнарын белгәч, ачу килеп барган идем, бик яхшылап бизәп җибәрделәр үземне...

• • •

Дәваханә регистратурасындагы белдерү: "Больничныйлар бирмибез! Монда хәтле килгәнсез, димәк, эшегезгә дә барып җитә аласыз!"

• • •

Табиб – авыру хатынга:

— Күбрәк саф һавада йөрегез һәм җылырак киенегез.

Хатын– иренә:

— Табиб миңа диңгезгә барып ял итәргә һәм чәшке тун киеп йөрергә кушты.

• • •

— Каравылчының 6 нчы разряды нәрсәне аңлата?

— Димәк, ул инде "Фән һәм тормыш"тагы кроссвордларны чишә.

• • •

Яңа диета: 3 көн — соклар гына; 5 көн — боткалар гына; 7 көн — алмалар гына. Аннан соң 3 се, 7 се... Аннан 40 ы...

• • •

Кипрда яшәүчеләр җир тетрәүләрдән бер дә курыкмый. Аларның уйлавынча, җимерелүләр никадәр күбрәк булса, шулхәтле туристлар да киләчәк!

• • •

Милли кадрлар тәрбияләү сәясәтенең бурычы – хөкүмәт органнарына акыллы, тәрбияле, тыйнак кешеләрне сайлап алу. Тыйнаклар урлаганнары белән мактанып йөрмәсеннәр, тәрбиялеләре тыйнакларның урлауларын күрмәсеннәр, ә акыллылар тыйнак булмаганнарны һәм тәрбиясезләрне, халык ризасызлык белдермәсен өчен, җайлап торырга тиеш.



(СКОРПИОН)

САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

№ 11 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры
һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.



Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
16+
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su
Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Зинаида ЗАХАРОВА



Сәкинә – күпне күрүче, күпне белүче, тагын да күбрәк белергә теләүче лыгырдавык хатын. Авыл яңалыкларын гына түгел, Америка, Африка яңалыкларын да аннан гына сора инде. Аны идарә, кибет, почта тирәсендә еш күрергә була. Быелгы елда кем өйләнәчәк, кемгә өйләнәчәк, кайсы гаиләдә бәби көтәләр, кемнәр ничек яши, кемнәр ялга кайсы якларга китәргә җыена – Сәкинә барын да белә. “Справочный бюро” дип кушамат та кушканнар үзенә. Ул моңа үпкәләми, киресенчә, горурлана булса кирәк. Көнбагыш янчыгы тотып көнозын урамда атынып йөри. Көннәрдәр бер көнне, ул авыл идарәсенең кабул итү бүлмәсендә таптанып торганда, рәис янына Газинур бабай килеп керде. Бабай белән авыл рәисенең сөйләшкән сүзләре Сәкинәгә аермачык диярлек ишетелеп торды. Сүз аерылышу турында бара иде, ахрысы. Рәиснең:

— Бу атнада вакыт тыгыз, икенче җомгада Гөлҗамал әби белән килерсез, паспортларыгызны да онытмагыз, — дигән сүзләрен ишеткәч, Сәкинәнең шиге калмады. Пар сандугачлар аерылышалар.

Ул бу яңалыкны да минуты-сәгате белән бөтен авылга таратты. Тикмәгә генә “Кем аерылмый, шулар белми аерылу газапларын”, дип җырламыйлардыр. Күтәрә алырмы икән Гөлҗамал әби бу хәлләрне? Юктыр шул, аерылышу башына җитәр инде әбекәйнең дип, бик кызгандылар әбине авыл хатыннары. Мескеннең нинди гөнаһы бар икән соң? Ул бит бөтен гомерен шул оятсыз Газинурга бирде. Гөлҗамал әби генә кеше итте бит аны. Йокыдан торышка төче коймагын пешереп, тормышларын тауга таба авыр йөк өстерәгән алаша кебек җигелеп үзе тартты. Балаларын үзе тәрбияләп үстерде. Шатлык безнең үрдәккә, биш кукәйдән биш бәбкә. Бу хәбәрне ишеткәч, балалары ни дияр? Ни дисеннәр, ычкынгандыр әткәй, диярләр шул. Яшь чагында Газинур читләр белән дә типтергән, дип сөйләделәр. Мөгаен, дөрестер. Утсыз төтен чыкмас. Кеше юкны сөйләмәс. Күрсәтәме Газинурың күрмәгәннәреңне! Иделгә таянма, ирeңә ышанма, дип халык белми әйтми. Халык әйтсә хак әйтә. Авыл хатыннары Гөлҗамал әбине әй, кызгандылар, ә Газинур картка булган нәфрәтләре арткан-нан-арта барды. Илле ел яшәгәннән соң нәрсә булган? Юк, берәү дә белми, ә белергә бик телиләр. Шуннан башланды да инде хәлләр. Кыскасы, кырмыска оясыдай гөж килде Таллы Бүләк авылы.

Авыл апалары өчен Гөлҗамал карчык белән Газинур картның аерылышулары чишә алмаслык башваткычка әйләнде. Мал-мөлкәтләрен ничек бүләрләр икән, дигән сорау тагын да авыррак иде. Бер сыер, бер сарай, бер мунча, бер йорт. Озак уйлый торгач, апаларда өч версия барлыкка килде. Апаларны бу версияләр өч төркемгә бүлде. Берәүләр:

— Газинур бабайның Себердә яшәүче уллары кайтып алып китә икән, — диде. Икенчеләр шуның нәкъ киресен сөйләде. Себергә Гөлҗамал әби китә икән, имеш. Өченче версия буенча, имеш, Газинур карт йортның үзенә тиешлесен сүтеп алып китә икән, диештеләр. Ә нигә Гөлҗамал әби китми? Нигә төп нигездә ул калырга тиеш? Газинур карт төзегән йорт ич ул, диеште кайберәүләр, бабайны яклап. Үзләрен күреп хәлләрен сорарга берәү дә батырчылык итмәде, җае да чыкмады.

— Болай да хәсрәтле башларыннан ашкан, каннарына тоз салу ярамас, — диеште берәүләр. Эчләрендә ут кайнаса да, борыннарыннан төтен чыгармыйлар. Ул тешләкләрдән сер алам димә, — диде икенчеләр.

— Кара эшне караңгыда эшләсәң дә, яктыга чыга, вакыты җиткәч белербез, — диеште авылның иң сабырлары.

Менә көткән җомга килеп җитте. Сәкинә иртән-иртүк, битен дә юмыйча, йомышы булмаса да, Таллы Бүләк парламентына китте. Сәкинә коридорда әби белән бабайны елмаеп каршы алды. “Присидәтел сезне күптән көтә”, — диде ул, шатлыгын яшерә алмыйча. Тегеләр рәис бүлмәсенә кереп китүгә, колагын ишеккә терәде. Эчке бүлмәдән сөйләшкән сүзләр аермачык булып ишетелеп тора. Әби белән бабай көлешеп тә алалар. Бу юләрләргә аерылышу зур шатлык микәнни, дип уйлап куйды Сәкинә.


— Безнең никахыбыз сәвит законнарыннан мең тапкыр олырак, дип тә әйтеп карадым, бабаңны тыңлата алмадым. Вакытыңны әрәм итеп йөргән өчен ачуланма инде, улым, — дип рәистән гафу үтенде әби.

Ә бабай: “Алтын туебызга балаларга сюрприз булсын дидем, карчык”, — диеп кеткелдәп көлеп җибәрде.

Сәкинә берни дә аңламый торганда, рәиснең: “Котлыйм, ниһаять сез законлы ир белән хатын булдыгыз”, — дигән сүзләрен ишетеп, чак егылмый калды.

Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Хатын-кызның иң ышанычлы билгесе.

2. Ни өчен кайбер әбиләрнең чәче шәмәхә төскә буялган?

3. Хатын-кызларның сизгерлеген ирләр ничек дип атыйлар?

4. Ватанның ашлык амбарларына нәрсә алып бара?

5. Нәрсә ул табигый кайтарып алу?

6. Исерек ир исерек хатын-кыздан нәрсәсе белән аерыла?

7. Һәрвакыт яхшы кәефле булу өчен нәрсә эшләргә кирәк?

ЖАВАПЛАР

1. Бизәнмәгән килеш өеңнән чыксаң, танышларыңны очратырсың. 2. Икенче мәртәбә килмәсен өчен, аларны СОБЕС махсус шундый төскә мана. 3. Каркылдау. 4. Хакимият коридоры. 5. Салымнар. 6. Ир кеше эчсә — бөтенесен оныта. Хатын-кыз эчсә — бөтенесен исенә төшерә. 7. Юкка-барга шатланырга өйрәнү. Әйтик, хезмәт хакына. Вак-төяк, әмма рәхәт.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемен укыгыз.
Журналыбызның 9 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **"ЯКТЫ ЕЛГА", "СӘЛИМӘКӘЙ".**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Н. БӘДРИЕВА (Теләче р-ны, Иске Җөри ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Иске Җөридән
Наилә БӘДРИЕВА!

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Виталий ФЕОКТИСТОВ



Илдар НӘФИЕВ



Владимир ИЖБОЛДИН



Рушан ГАТАУЛЛИН

